**ТАТАРСТАН Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**муниципаль беремлеге**
**Емелькино авылы**

**Республика ТАТАРСТАН**
**Аксубаевский**
**муниципальный район**
**муниципальное образование**
**село Емелькино**

# Совет Емелькинского сельского поселения

423056, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Емелькино, ул. Центральная д.16
Тел.(8-84344-4-76-22) ОГРН 1021605364980, ОКПО 94318599,ИНН/КПП 1603000796/160301001

## КАРАР

**2021 ел, 23 март** **№ 21**

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымны һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләттерүгә өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр турында» 01.03.2021 ел, №16 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымны һәм пеня һәм штрафлар буенча бурычны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 01.03.2021 ел, №16 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Карарның преамбуласында «Түләтүгә өметсез дип танылган түләнеп бетмәгән салымны һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычны бетерү Тәртибен һәм түләнеп бетмәгән салымны, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар Исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2010 ел, 19 август, № ЯК-7-8/393 боерыгы» сүзләрен «Түләтүгә өметсез дип танылган түләнеп бетмәгән салымны һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычны бетерү Тәртибен һәм түләнеп бетмәгән салымны, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар Исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2019 ел, 2 апрелҗ, № ММВ-7-8/164 боерыгы» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 1 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. 2 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Емелькино авыл җирлеге Советының финанс һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе: Н.И.Михайлова